Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

03.11.2020 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 35 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең Өч Нарат торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2021 нче елда Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Өч Нарат авылының Татарстан урамы буенча автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/ikshurma бастырып чыгарырга.

Иске Икшермә авыл
җирлеге башлыгы урынбасары А.И.Биккинин